**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

от 10.02.2022 г №17-01

**Актаныш муниципаль районының 2021 нче елда социаль-икътисадый үсеш нәтиҗәләре һәм 2022 нче елга бурычлары турында**

Актаныш муниципаль районы Башлыгы Фәттахов Энгель Нәваповичның Актаныш муниципаль районының 2021 нче елда социаль-икътисадый үсеш нәтиҗәләре һәм 2022 нче елга бурычлары турында докладын тыңлаганнан соң, Актаныш муниципаль район Советы **КАРАР БИРӘ**:

1. Актаныш муниципаль район Башлыгы Фәттахов Энгель Нәваповичның Актаныш муниципаль районының 2021 нче елда социаль-икътисадый үсеше турындагы отчетын искә алырга.
2. 2022 нче елга куелган бурычларны планлы рәвештә тормышка ашыру максатыннан һәм җирлекләрдә булып узган отчет җыелышларында гражданнардан кергән сорауларны хәл итү өчен юл картасы булдырып, аның үтәлешен тәэмин итәргә (кушымта теркәлә).
3. Куелган бурычларны планлы рәвештә тормышка ашыруда җаваплы итеп район Советының даими комиссияләрен билгеләргә.
4. Карар үтәлешен тәэмин итүне Актаныш муниципаль район Советы рәисе урынбасары И.И.Габдулхаевка йөкләргә.

Актаныш муниципаль район
Советы рәисе Э.Н.Фәттахов

Актаныш муниципаль
район Советының
10.02.20022 ел, №17-01
карарына кушымта

2022 нче елга район Советы тарафыннан
куелган бурычлар

| № | Бурычлар | Жаваплы |
|---|---|---|
| 1 | Районның социаль-икътисади үсешендә халыкның яшәү сыйфатын яхшыртуда цифрлаштыру технологияләрен инструмент буларак актив кертергә һәм кулланырга. | Сираева Л.Р. |
| 2 | Актаныш районының экономик үсешен инвестицияләр, программалар аша көчәйтү. Сәнәгать мәйданчыгына резидентлар җәлеп итәргә. Маркетплейс интсрументлары аркылы кече һәм урта эшмәкәрлекне көчәйтергә. | Сираева Л.Р. |
| 3 | Районыбызда барлык милләт вәкилләренең тыныч дустанә яшәвен тәэмин итәргә, милли мәсьәләләрне бердәм хәл итәргә. | Нурлыева Л.Ф.<br>Авыл җирлеге башлыклары |
| 4 | «Милли проектлар» федераль дәүләт, республика программаларында актив катнашып районга төзелеш, социаль мәсьәләләр өчен финанслар җәлеп итәргә. | Габдулхаев И.И. |
| 5 | Демографик торышны исәпкә алып, район Советы карары белән кабул ителгән «2021-2023 елларда Актаныш муниципаль районында демографик хәлне яхшырту» муниципаль программасын тормышка ашыруны дәвам итәргә. | Хаев А.Р.<br>Авыл җирлеге башлыклары |
| 6 | 2021-2023 елларда «Актаныш районы авыл хужалыгы үстерү” программасы кысаларында билгеләнгән күрсәткечләргә ирешү, хуҗалыкларда инновацион технологияләр кулланып эш оештыруны тәэмин итәргә. Авыл хуҗалыгы тармагында федераль программалар катнашу эшен активлаштырырга. Шәхси, фермер хуҗалыкларда мал баш санын арттыру өчен эффектив эш оештырырга. | Салимгараев Н.А.<br>Авыл җирлеге башлыклары |
| 7 | Авыл җирлекләрендә бюджетны тулыландыру өчен салымнарны вакытында туплага, көнкүреш мәсьәләләрне хәл итү өчен үзара салым программасыннан тулаем файдаланырга. | Габдулхаев И.И.<br>Авыл җирлеге башлыклары |
| 8 | Мәгариф өлкәсендә заман таләпләренә җайлашып, үзенең сәламәтлеген даими кайгыртып, җәмгыяттә уз урынын таба алырдай шәхесләр тәрбияләү өчен шартлар булдырырга, үстерергә. | Нурлыева Л.Ф. |
| 9 | Мәдәният өлкәсендә үзәкләштерелгән структураны булдыру, Ә.Авзалова исемендәге район мәдәният йортының Актаныш халык театрына “дәүләт” статусы алу максатыннан планлы эш алып барырга. | Нурлыева Л.Ф. |
| 10 | Район гражданнарының сәламәтлеген саклау һәм ныгыту максатыннан физкультура спорт белән даими шөгыльләнүчеләр санын арттырырга, спорт мәйданчыклары булдырырга | Нурлыева Л.Ф.<br>Гарипов Р.И. |